КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 август

г.Казань

№ 746

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 февраль, 151 нче карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татар-стан

Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2022 ел, ның 22 февраль, 151 нче карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасында җирле үзидарәне төзүгә һәм үстерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 пунктта:

унынчы абзацта «максатлар,» сүзен төшереп калдырырга;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидияләр алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $26^{92}$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

18 пунктның бишенче абзацында «максатлар һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

23 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Тәртипнең 3 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы тугызынчы абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин